**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№6956**
**03.08.2023**

Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә ташландык, хуҗасыз транспорт чараларын ачыклау, исәпкә алу, күчерү, саклау, утильләштерү тәртибен раслау турында» 2017 елның 23 августындагы 4916 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә ташландык, хуҗасыз транспорт чараларын ачыклау, исәпкә алу, күчерү, саклау, утильләштерү тәртибен раслау турында» 2017 елның 23 августындагы 4916 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) преамбулада «Шәһәр Советының 2012 елның 20 сентябрендәге 21/8 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре» сүзләрен «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре» сүзләренә алмаштырырга;

2) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның Комсомол районы хакимияте Башлыгы Л.И. Әхмәтҗановка, Башкарма комитетның Үзәк районы хакимияте Башлыгы Э.Р. Фәттаховка, Башкарма комитетның Автозавод районы хакимияте Башлыгы В.Х. Харисовка йөкләргә.»;

3) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә ташландык, хуҗасыз транспорт чараларын ачыклау, исәпкә алу, күчерү, саклау, утильләштерү тәртибендә:

- 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Ташландык транспорт чарасының алгы пыяласына, ул булмаган очракта башка күренә торган урынга, транспорт чарасының хуҗасы таләп төзелгән датадан башлап өч эш көне эчендә аны транспорт чараларын ремонтлау, саклау яки кую өчен билгеләнгән урыннарга күчереп куярга тиешлекне күрсәтеп, әлеге Тәртипкә 2 нче кушымтада каралган форма буенча таләп беркетелә.»;

- 7 пунктта «ике эш көне эчендә» сүзләрен «шул ук көнне» сүзләренә алмаштырырга;

- 8 пунктта «14-16 пунктларында» сүзләрен «12-14 пунктларында» сүзләренә алмаштырырга;

- 9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Яр Чаллы шәһәре буенча Эчке эшләр идарәсе тарафыннан транспорт чарасының хуҗасы турында мәгълүмат бирелгән булса, район Хакимиятенең вазыйфаи затлары Яр Чаллы шәһәре буенча ЭЭМ идарәсе тарафыннан мәгълүматлар бирелгән вакыттан башлап өч эш көне эчендә, әлеге Тәртипкә 3 нче кушымтада каралган форма буенча транспорт чараларын ремонтлау, саклау яки кую өчен билгеләнгән урыннарга транспорт чарасын транспортлау (күчерү) кирәклеге турындагы таләпне тапшыру өчен, транспорт чарасы хуҗасына хәбәр итү буенча гамәлләрне башкаралар һәм Яр Чаллы шәһәре буенча ЭЭМ идарәсе тарафыннан мәгълүматлар бирелгән вакыттан башлап өч эш көне эчендә милекче табылмаган яисә Яр Чаллы шәһәре буенча ЭЭМ идарәсенә милекче турында мәгълүматлар бирелмәгән булса, әлеге Тәртипкә 5 нче кушымтада каралган форма буенча хуҗасыз, ташландык транспорт чарасын күчерү турында акт төзиләр һәм гражданнарның тормыш иминлегенә куркыныч тудыра, юл хәрәкәтенә, махсус һәм башка транспорт хәрәкәтенә комачаулый, муниципаль берәмлек территориясен, юл челтәрен һәм ишегалды территорияләрен җыештыруда кыенлык тудыра торган хуҗасыз, ташландык транспорт чарасын саклау мәйданчыгына күчерү буенча кичектергесез гамәлләрне башкаралар;»;

- 10, 11 пунктлар үз көчен югалткан дип танырга;

- 12-14 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Транспорт чарасында дәүләт номеры булмаган, шулай ук кузов номеры турында күренеп торган мәгълүмат булмаган очракта, мондый транспорт чарасы ачыкланган көнне Комиссия тикшерү үткәрә, аның нәтиҗәләре буенча әлеге Тәртипкә 1 нче кушымтада каралган форма буенча акт төзелә.

13. Хуҗасыз транспорт чарасының алгы пыяласына, ул булмаган очракта башка күренә торган урынга, транспорт чарасының хуҗасы таләп төзелгән датадан башлап өч эш көне эчендә аны транспорт чараларын ремонтлау, саклау яки кую өчен билгеләнгән урыннарга транспортларга тиешлекне күрсәтеп, әлеге Тәртипкә 2 нче кушымтада каралган форма буенча таләп беркетелә.

14. Хуҗасыз транспорт чарасы әлеге Тәртипнең 13 пунктында күрсәтелгән срок эчендә алынмаса, район Хакимиятенең вазыйфаи затлары әлеге Тәртипкә 5 нче кушымтада каралган форма буенча хуҗасыз, ташландык транспорт чарасын күчерү турында акт төзиләр һәм гражданнарның тормыш иминлегенә куркыныч тудыра, юл хәрәкәтенә, махсус һәм башка транспорт хәрәкәтенә комачаулый, муниципаль берәмлек территориясен, юл челтәрен һәм ишегалды территорияләрен җыештыруда кыенлык тудыра торган хуҗасыз, ташландык транспорт чарасын саклау мәйданчыгына күчерү буенча кичектергесез гамәлләрне башкаралар;»;

- 15, 16 пунктлар үз көчен югалткан дип танырга;

- 17 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17. Гражданнарның тормыш иминлегенә куркыныч тудыра, юл хәрәкәтенә, махсус һәм башка транспорт хәрәкәтенә комачаулый, муниципаль берәмлек территориясен, юл челтәрен һәм ишегалды территорияләрен җыештыруда кыенлык тудыра торган, ачыкланган хуҗасыз, ташландык транспорт чарасын күчерү (транспортлау) буенча эшләр гамәлдәге законнар таләпләренә туры китереп сайлана торган махсуслаштырылган оешма тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Гражданнарның тормыш иминлегенә куркыныч тудыра, юл хәрәкәтенә, махсус һәм башка транспорт хәрәкәтенә комачаулый, муниципаль берәмлек территориясен, юл челтәрен һәм ишегалды территорияләрен җыештыруда кыенлык тудыра торган, ачыкланган хуҗасыз, ташландык транспорт чарасын күчерү (транспортлау) шәһәр бюджеты акчалары хисабына гамәлгә ашырыла, тотылган чыгымнар соңыннан объект хуҗасы хисабына компенсацияләнә.»;

- 23 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«23. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенә караган җир участокларында урнашкан, аларның базар бәясе «Россия Федерациясендә бәяләү эшчәнлеге турында» 1998 елның 29 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә бәйсез бәяләүче тарафыннан өч мең сумнан түбән билгеләнгән ташландык транспорт чаралары, Россия Федерациясе Граждан кодексының 226 статьясында билгеләнгән тәртиптә, Башкарма комитет карарын кабул итү юлы белән, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге мөлкәтенә кертеләләр.»;

- 24 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«24. Транспорт чарасының бәясе 23 пунктта күрсәтелгән бәядән артып киткән очракта, әгәр милекче билгеле булмаса яки саклау срогы чыкса, шәһәр Башкарма комитеты андый транспорт чарасын хуҗасыз дип тану һәм аңа муниципаль милек хокукын тану турында гариза белән судка мөрәҗәгать итә.».

- кушымтада каралганча 5 нче кушымта өстәргә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның Комсомол районы хакимияте Башлыгы Л.И. Әхмәтҗановка, Башкарма комитетның Үзәк районы хакимияте Башлыгы Э.Р. Фәттаховка, Башкарма комитетның Автозавод районы хакимияте Башлыгы В.Х. Харисовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2023 елның 3 августындагы
6956 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә ташландык, хуҗасыз транспорт чараларын ачыклау, исәпкә алу, күчерү, саклау, утильләштерү тәртибенә
5 нче кушымта

Хуҗасыз, ташландык транспорт чарасын күчерү турында акт

"__" ________ 20__ ел ___ сәг. ___ мин.__________________________ адресы буенча урнашкан түбәндәге хуҗасыз, ташландык транспорт чарасын "__" _________ 20__ ел ___ сәг. ___ мин. күчерү турында әлеге акт төзелде:

1) транспорт чарасының маркасы, төсе __________________________________________;

2) дәүләт теркәү билгесе (булганда) ____________________________________________,

башка идентификация мәгълүматлары ____________________________________________;

3) транспорт чарасына тулы тасвирлама __________________________________________

_______________________________________________________________________________;

4) төяү һәм күчерү ысулы, төяү һәм күчерүне гамәлгә ашыручы оешма

_______________________________________________________________________________

_______________________________________________________________________________

_______________________________________________________________________________;

5) гражданнарның тормыш иминлегенә куркыныч тудыра, юл хәрәкәтенә, махсус һәм башка транспорт хәрәкәтенә комачаулый, муниципаль берәмлек территориясен, юл челтәрен һәм ишегалды территорияләрен җыештыруда кыенлык тудыра торган, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан транспорт чарасын тикшерү акты төзелгән һәм хуҗасыз, ташландык транспорт чарасы хуҗасына хәбәр ителгән дата, вакыт ______________________________________________;

6) милекчегә хәбәр итү турында мәгълүмат яисә транспорт чарасының хуҗасы турында мәгълүматлар булмау турында мәгълүмат ________________________________;

7) милекче тарафыннан транспорт чарасын күчерү турында таләп үтәлмәү турында мәгълүмат _________________________________________________________________.

Кушымталар:

1) транспорт чарасының эчендә булган, күренеп торган мөлкәт исемлеге;

2) транспорт чарасының эчендә булган мөлкәтнең фотосурәте;

3) транспорт чарасын тикшерү актының күчермәсе, транспорт чарасын күчерү турында таләпнең күчермәсе.

Район Хакимияте вәкиле ____________________________________________________________

(Ф.И.А.и., вазыйфа, имза, имза расшифровкасы)

Хуҗасыз, ташландык транспорт чарасының хуҗасы ___________________________________

(Ф.И.А.и., имза, имза расшифровкасы)

Шаһит 1: ____________________________________________________________________________

(Ф.И.А.и., имзаны теркәү урыны, имза расшифровкасы)

Шаһит 2: ____________________________________________________________________________

(Ф.И.А.и., имзаны теркәү урыны, имза расшифровкасы)

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева